ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«27 »декабрь 2021 ел № 184-р

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды ярышы» чаңгы ярышлары үткәрү турында

Чаңгы узышларын популярлаштыру һәм үстерү, халык белән сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, физкультура-савыктыру һәм спорт-массакүләм эшне камилләштерү, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә этәргеч бирә торган шартлар тудыру, иң көчле спортчыларны һәм командаларны ачыклау, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында ярышларда катнашучылар арасында спорт осталыгын арттыру максатларында:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды ярышы» чаңгы ярышлары үткәрелү датасын 2021 елның 29 декабрендә, чараны уздыру урыны - Әгерҗе шәһәренең «Орешник» мәдәният һәм ял паркы дип билгеләргә.

2.Расларга:

- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды ярышы» чаңгы ярышлары үткәрү турында Нигезләмә (1 нче кушымта);

- «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды ярышы» чаңгы ярышлары үткәрүгә чыгымнар сметасын (2 нче кушымта).

3.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының МБУ «Спорт мәктәбе»нә:

- “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды ярышы” чаңгы ярышларын оештырырга һәм үткәрергә;

- “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында Яңа ел алды кичке узышы” чаңгы ярышлары буенча массакүләм чаңгы ярышлары үткәрү урынын әзерләүне оештырырга.

4. МКУ «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе»нә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф учреждениеләрен әлеге күрсәтмә белән таныштырырга һәм аларның «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды узышы» чаңгы ярышларында катнашуын тәэмин итәргә.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә һәр оешмадан (учреждениедән) кимендә 3 кеше катнашырга тәкъдим итәргә.

6. «Әгерҗе үзәк район хастаханәсе» ДАССУга спорт чарасы - “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды узышы” чаңгы ярышлары чорында медицина ярдәме күрсәтүне тәкъдим итәргә.

7.Россия Эчке эшләр министрлыгының Әгерҗе районы буенча бүлегенә чаңгы ярышлары уздырганда «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды ярышы» ярышларын куркынычсызлыгын һәм озата баруны тәкъдим итәргә.

8.«Татмедиа» АҖ филиалы - Әгерҗе муниципаль районы «Әгерҗе хәбәрләре» газетасы редакциясенә, «Әгерҗе радиосы» муниципаль бюджет учреждениесенә «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды ярышлары» чаңгы ярышларын уздыру барышы һәм нәтиҗәләре турында массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга тәкъдим итәргә.

9. Әлеге күрәтмәне «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

10. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының спорт һәм туризм бүлеге башлыгы Л.С. Имановага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

«Килешенгән»

Татарстан Республикасы

Әгерҗе муниципаль районынын

Чангы узышлары һәм биатлоны федерациясе рәисе

________________А.Е. Сабитов

«Килешенгән»

Татарстан Республикасы

Әгерҗе муниципаль районы башлыгы

________________А.Р. Вәлиев

«Раслыйм»

ТР Әгерже муниципаль районы

Башкарма комитетының

спорт бүлеге җитәкчесе

____________Л.С. Иманова

«Раслыйм»

ТР Әгерже муниципаль районы

"Спорт мәктәпе" директоры»

________________ И.И. Чуков

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яна ел алды ярышы» чаңгы ярышлары үткәрү турында Нигезләмә

**1. Максатлар һәм бурычлар.**

-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында чангы ярышларын пропагандалау һәм популярлаштыру;

-сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм ярышларда катнашучыларның спорт осталыгын арттыру;

- физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә мотивацияли торган шартлар тудыру;

-климат шартларына һәм хезмәт графигына карамыйча, тәүлекнен теләсә кайсы вакытында спорт белән шөгыльләнүне пропагандалау.

**2. Уздыру урыны һәм вактыт.**

Ярышлар 2021 елның 29 декабрендә Әгерҗе шәһәрендә «Орешник» паркында уздырыла.

Старт 16.00 сәгатьтә.

**3. Ярышлар үткәрү һәм җитәкчелек итү.**

Ярышларның гомуми җитәкчелеген ТР Әгерже муниципаль районы Чаңгы узышлары һәм биатлон федерациясе, ТР Әгерже муниципаль районы башкарма комитетының Спорт бүлеге алып бара. Турыдан-туры үткәрү Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын «Спорт мәктәбе» МБУ һәм баш судьялар коллегиясенә йөкләнә.

Баш судья - Чечегов С.В.

Баш сәркәтип - Чечегов Т.С.

Элемтә телефоннары: 8(85551)2-34-20, 89225213996.

**4. Ярышларда катнашучылар һәм программа.**

Ярышларга медицина рөхсәте булган һәркем катнаша ала.

## 5. Программа һәм уздыру форматы

14.30-15.20 - ярышларда катнашучыларны теркәү, мандатлы комиссия эше, старт номерлары бирү
15.40 - ярышларны тантаналы ачу
16.00 - ярышлар башлану
Ярышлар тәмамлангannan соң бүләкләү.

Пролог:

| № | Категория | Дистанция | |
|---|---|---|---|
| | | **Егетләр, ир-атлар** | **Кызлар, хатын-кызлар** |
| 1. | 2014 елда туган һәм яшьрәк | **500 м** | **500 м** |
| 2. | 2012-2013 елда туган. | **500 м** | **500 м** |
| 3. | 2010 – 2011 елда туган. | 1 км | 1 км |
| 4. | 2008 – 2009 елда туган | 1 км | 1 км |
| 5. | 2006-2007 елда туган | 2 км | 2 км |
| 6. | 2005 - 1982 елда туган | 3 км | 2км |
| 7. | 1981-1972 елда туган | 3 км | 2 км |
| 8. | 1971 елда туган һәм өлкәнрәк | 2 км | 2 км |

Финал йөгерешендә ярышларда катнашучылар шул ук дистанцияләргә йөгерәләр.
Финал А: беренче 6 урынны алган спортчылар эләгә
Финал В: 7 дән 12 урынга кадәр алган спортчылар эләгә
Пролог масс-старт рәвешендә уза, йөреш ирекле

## 6. Бүләкләү

Җиңүчеләр һәм призёрлар грамоталар һәм медальләр белән бүләкләнә.

## 7. Финанслау

Трасса һәм судьялык әзерләүгә бәйле чыгымнар - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Спорт мәктәбе» МБУ исәбеннән.

## 8. Ярышларда катнашучыларның һәм тамашачыларның иминлеге.

Барлык катнашучылар, тренерлар, укытучылар, судьялар һәм тамашачылар яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) таралуны булдырмау өчен куркынычсызлык чараларын үтәргә тиеш.

Судьялар, тренерлар, укытучылар һәм катнашучылар чаңгы базасында, ярышларда катнашучыларны теркәгәндә, маскаларда булырга һәм 1,5 м дистанцияне сакларга тиеш.

***Әлеге нигезләмә ярышларга рәсми чакыру булып тора!***

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында кичке Яңа ел алды ярышы» чаңгы ярышлары үткәрүгә чыгымнар сметасы

<u>Бүләкләү материаллары:</u>

| | |
|---|---|
| Медальләр | 48 шт. х 150 сум = 7 200,00 сум |
| Грамоталар | 48 шт. х 20 сум = 960,00 сум |

ГСМ:
Буран (АИ 92): 60 л. х 45,50 сум = 2 730,00 сум

**Барлыгы: 10 890,00 сум**